# Мөхәррәм ае

شهر الله المحرم

اللغة التترية

ALSARHAAN.COM

شهر الله المحرم هو أول شهور السنة الهجرية.

Хиҗри елның беренче ае – Мөхәррәм ае.

وهو أحد الأشهر الحُرم الأربعة التي ذكرها الله تعالى بقوله:

Һәм бу ай Аллаһ искә алган дүрт хәрам кылынган айларның берсе:

إن عدة الشهور عند الله اثنا عشر شهرا في كتاب الله يوم خلق السماوات والأرض منها أربعةٌ حرم.

"Аллаһ хозурындагы китапта айлар саны унике, җирне һәм күкләрне яраткан көннән бирле, ул унике айдан дүртесе хәрам кылынган айлар".

( وهي ذو القعدة وذو الحجة والمحرم ورجب. )
-كما بينها النبي صلى الله عليه وسلم.-

Пәйгамбәребез ﷺ аңлатып биргәнчә алар: Зөл-Кәгъдә, Зөл-Хиҗҗә, Мөхәррәм, Раҗәб айлары.

ومن عظيم شرف هذا الشهر أنّ النبي صلى الله عليه وسلم أضافه إلى اسم الله تعالى ،
فسماه شهر الله  المحرم تشريفا له وتعظيما.

Шулай ук бу айның бөеклегеннән, Пәйгамбәребезнең ﷺ шушы айны Бөек Аллаһ исеменә кушып аны Аллаһ ае Мөхәррәм дип исемләве.

فعن أبي هريرة رضي الله عنه قال:
قال رسول الله صلى الله عليه وسلم:
أفضل الصيام بعد رمضان شهر الله المحرم.
وأفضل الصلاة بعد الفريضة صلاة الليل

Абу Хурайрадан хәбәр ителә:
Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: "Рамазан аеннан соң булган иң яхшы ураза - Аллаһның ае Мөхәррәм аенда, һәм фарыз кылынган намаздан соң иң яхшы намаз – төннең өченче өлешендә укылган намаз".

و يتأكد تحريم الظلم في هذا الشهر العظيم كما يتأكد تحريمه في غيره من الأشهر الحرم.

( لقوله تعالى: فلا تظلموا فيهن أنفسكم.)

Аллаһның "Бу айларда үз-үзегезгә золымлык кылмагыз"- дигән сүзләренә нигезләнеп, Пәйгамбәребез калган хәрам кылынган айларда золымлык кылу тыелганына инанган кебек, шушы бөек айда да золымлык кылу хәрам кылынганына ныклап ышанган.

وإن كان الظلم في كل وقت حراما.

Чынлыкта, золымлык һичкайчан хәрам кылынган.

فعن ابن عباس في قوله تعالى: فلا تظلموا فيهن أنفسكم أي في كلهن.

Һәм ибн Гәббәс шушы аятькә тәфсир биргәнчә: " Шушы айларда, ягъни үнике айның һәммәсендә дә, үз-үзегезгә золымлык кылмагыз".

ثم اختص من ذلك أربعة أشهر

һәм шуннан соң Раббыбыз шушы дүрт айны аерып куйган.

فجعلهن حرامًا وعظّم حرماتهن وجعل الذنب فيهن أعظم والعمل الصالح والأجر أعظم

Аларны хәрам айлары дип билгеләгән, һәм анда эшләнгән гөнаһлар өчен җәсасын арттырган, һәм анда эшләнгән изге гамәлләр өчен дә әҗерен арттырган.

والصوم في شهر الله المحرم من أفضل التطوع.

Мөхәррәм аенда ураза тоту – кешенең үзе теләп кылган гамәлләрдән иң яхшысы.

وهو أفضل ما يكون من الصيام بعد رمضان.

һәм Рамазан аеннан соң тотылган уразалардан да иң яхшысы.

ففي الحديث أن النبي صلى الله عليه وسلم سئل : أي الصلاة أفضل بعد المكتوبة.
وأي الصيام أفضل بعد شهر رمضان
فقال : أفضل الصلاة بعد الصلاة المكتوبة الصلاة في جوف الليل
وأفضل الصيام بعد شهر رمضان صيام شهر الله

Пәйгамбәребездән ﷺ: "Фарыз кылынган намазлардан соң нинди намаз иң яхшысы, һәм Рамазан ае уразасыннан соң нинди ураза иң яхшысы",- дип сорадылар. Ул: "Фарыз кылынган намазлардан соң иң яхшысы – төн уртасында укылган намаз, һәм Рамазан аенда тотылган уразадан соң иң яхшысы – ул Мөхәррәм ае уразасы",- дип әйтте.